БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
11 сентябрь 2025 ел

**КАРАР**
№ 339

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2016 елның 16 сентябрендәге 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә (2024 елның 13 декабрендәге 295 номерлы редакциядә) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3.2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац:

«13) хезмәт өлкәсендә социаль партнерлык системасын үстерүне һәм район җирле үзидарә органнарының Профсоюзлар (профсоюзлар берләшмәләре), эш бирүчеләр (эш бирүчеләр берләшмәләре) белән социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм шуларга бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне хезмәт законнары нигезендә җайга салу мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итү.»;

1.2. Нигезләмәнең 4 бүлегендәге 4.1. пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) социаль партнерлыкны үстерү өлкәсендә:

түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- социаль-хезмәт һәм аларга турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга салу өлкәсендә социаль партнерлык принципларын гамәлгә ашыру;

- районда социаль партнерлык мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында, районның «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында мәгълүмати тәэмин итү;

- районның социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өч яклы территориаль комиссия (алга таба – территориаль комиссия) эшчәнлеге;

- район җирле үзидарә органнарының хезмәт һәм аларга турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый акт проектларын район Советына кертелгәнче яисә район җирле үзидарә органнары алар буенча карарлар кабул иткәнче территориаль комиссия утырышларында карау;

- территориаль комиссия карарларын, ә җайга салынмаган каршылыклар булганда - территориаль комиссиягә җибәрелгән хезмәт өлкәсендәге норматив хокукый акт проектларына карата якларның фикерләрен район Советына җиткерү һәм аларны районның җирле үзидарә органнары тарафыннан карау;

- профсоюзлар (профсоюз берләшмәләре), эш бирүчеләр (эш бирүчеләрнең берләшмәләре) белән социаль партнерлык кысаларында социаль-хезмәт һәм аларга турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар проектларын килештерү;

- профсоюз ягы һәм эш бирүче як вәкилләрен район башкарма комитеты тарафыннан төзелә торган комиссияләр, эшче төркемнәр, социаль-хезмәт мәсьәләләре буенча Советлар составына кертү һәм аларның эшендә катнашу.»;

1.3. Нигезләмәнең 4 бүлегендәге 4.1 пунктының 9 пунктчасын Нигезләмәнең 4 бүлегенең 4.1 пунктының 10 пунктчасы дип санарга;

1.4. Нигезләмәнең 5 бүлегендәге 5.8 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- террорчылык идеологиясе һәм неонацизм идеяләре таралуга каршы тору буенча вазыйфалар башкара.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Балтач муниципаль районының Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Хәйретдиновка, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче районара салым инспекциясендә, әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләрне һәм юридик затларның бердәм дәүләт реестрында башка үзгәрешләрне теркәгәндә, шул максатларда кирәкле гаризаларга һәм башка документларга кул кую, законнарда каралган тәртиптә һәм срокларда башка гамәлләр һәм формальлекләр башкару өчен вәкаләт биреп, мөрәҗәгать итүче буларак чыгыш ясау хокукы бирергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р.Нотфуллин